# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылында
гражданнардан үзара салым кертү турында

**18.03.2024 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 3 номерлы карары белән «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең Текмәле торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең Текмәле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылы гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең Текмәле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 18.11.2023 № 1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең Текмәле авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 18.11.2023 № 2 гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« 1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү) Текмәле торак пунктында.».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

(http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина